DOI: 10.26907/2311-2042-2023-21-2-163-168

# THE WORLD-FAMOUS TURCOLOGIST ZAKIEV MIRFATIYKH SON OF ZAKI

**Gulshat Raisovna Galiullina,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
Gulshat.Galiullina@kpfu.ru.

**Alfia Shavketovna Yusupova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
alyusupova@yandex.ru.



**Zakiyev Mirfatykh Zakiyevich** (1928–2023) was a scholar, Tatar linguist, doctor of philology (1963), professor (1964), head of the Department of Tatar Language and Literature at Kazan State University (now – Kazan Federal University) (1960–1965), the rector of the Kazan State Pedagogical Institute (1967–1986), director of the Institute of Language, Literature and History of the Kazan branch of the USSR Academy of Sciences (later the Institute of Language, Literature and History (1986–2000), head of the Linguistics Department of the Institute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan (1986–2014), a chief researcher of the Department of Lexicology and Dialectology (2014–2023), consulting professor at Kazan Federal University (2020–2023), academician of the Academy of Sciences of the Republic of

**Зәкиев Мирфатыйх Зәки улы** (1928–2023) – галим, татар теле белгече, филология фәннәре докторы (1963), профессор (1964), Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире (хәзер КФУ) (1960–1965), Казан дәүләт педагогия институты ректоры (1967–1986), СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты (соңрак Татарстан фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) директоры (1986–2000), Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият, сәнгать институты тел белеме бүлеге мөдире (1986–2014), лексикология һәм диалектология бүлегенең баш гыйльми хезмәткәре (2014–2023) Казан федераль университетының профессор-консультанты (2020–2023), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе

**Закиев Мирфатих Закиевич** (1928–2023) – ученый, татарский языковед, доктор филологических наук (1963), профессор (1964), заведующий кафедрой татарского языка и литературы Казанского государственного университета (ныне КФУ) (1960–1965), ректор Казанского государственного педагогического института (1967–1986), директор Института языка, литературы и истории Казанского филиала АН СССР (позже Института языка, литературы и истории) (1986–2000), заведующий отделом языкознания Института языка, литературы, искусства АН РТ (1986–2014), главный научный сотрудник отдела лексикологии и диалектологии (2014–2023), профессор-консультант Казанского федерального университета (2020–2023), академик АН РТ (1991), заслуженный деятель науки ТАССР (1970), заслуженный деятель науки РСФСР (1976),

Tatarstan (1991), Honored Scientist of the TASSR (1970), Honored Scientist of the RSFSR (1976), laureate of the State Prize of the Republic of Tatarstan in the Field of Science and Technology (1994), emeritus professor of Kazan University (2013).

академигы (1991), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1970), РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1976), Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1994), Казан университетының атказанган профессоры (2013).

лауреат Государственной премии Республики Татарстан в области науки и техники (1994), заслуженный профессор Казанского университета (2013).

Mirfatykh Zakiyevich Zakiyev occupies a very important place in the constellation of scholars who left a deep mark on the history of Tatar linguistics.

The scholar was born on August 14, 1928 in the village of Zaipe, in the Yutazy (now Bauly) Region of the Republic of Tatarstan. In his wartime childhood, he had a rural lifestyle, experiencing the burden of physical labor and having to do the work that older men used to do. In 1946, M. Zakiev entered the Department of Tatar Philology of Kazan State University. His qualities, such as desire for knowledge and science, the sense of responsibility allowed him to graduate from the university in 1951 with excellent marks and undertake a postgraduate course at the Kazan branch of the Academy of Sciences of the USSR. In 1954, he completed his graduate studies ahead of time by presenting his thesis for the Candidate of Philology degree. From that year on, a new period in the scholar's life – the period of Kazan State University began: the young professional started teaching as a senior teacher in the Department of Tatar Language and Literature. The erudite young scholar was soon involved in social activities, he was appointed the official of the Communist Party organization at the History and Philology Faculty of the University. In 1960–1965, Mirfatykh Zakiyev was appointed the head of the Tatar Language and Literature Department.

In 1963, he presented his thesis "Syntactic structure of the Tatar language" for the Doctor of Philology degree [1]. It is worth noting that M. Zakiyev was one of the first in the field of Tatar linguistics who comprehensively studied Tatar syntax, prepared a research work and implemented a course on Tatar syntax for students of higher education institutions. Later, his work served as an example for other Turkic peoples. His research works "Modern Tatar Literary Language. Syntax" [2], "Syntax Structure of the Tatar Language" [3] and "Syntactic Structure of the Tatar Language" [4], prepared in different years, are currently considered to be the most worthy ones, fully reflecting the grammatical structure of the Tatar language.

The second very responsible period of the scholar's life was connected with the Kazan State Pedagogical Institute. Actively involved in scientific research, M. Zakiyev also devoted much time to the social and organizational work and in 1965 he was appointed vice-rector of the Kazan State Pedagogical Institute, in 1967 he became its rector. He worked in this position until 1986. In 1980–1991, he simultaneously performed the duties of the Chairman of the Supreme Council of the TASSR.

In 1986, Mirfatykh Zakiyev became the director of the Department of Language, Literature and History at the Kazan branch of the Academy of Sciences of the USSR, which later achieved the independent status of the Institute, and he greatly contributed to its development. The scholar worked in this position until 2000. From 1986 to 2014, he was the head of the Department of Linguistics of the Tatarstan Academy of Sciences. From 2014 until his death, he worked as a chief researcher of the Department of Lexicology and Dialectology of the same institute.

No matter where M. Zakiev worked, he did not lose contact with Kazan University where he got his education and started his career. For many years, as a visiting professor, he taught students, assistant professors and supervised the research of graduate students. In 2020–2023, he was a professor-consultant of Kazan Federal University.

Mirfatykh Zakiyev was a world-renowned, encyclopedic scholar and teacher. He was a person who played a key role in the formation and development of modern Tatar linguistics. His numerous works are devoted to various branches of the Tatar language, the Tatar people, the emergence of the Tatar language and the problems of ethnogenesis.

As a linguist and a philologist of wide interests, Mirfatykh Zakiev often spoke at research conferences. Turkologists always looked forward to the his speeches at the conferences held in Moscow, St. Petersburg, Baku, Tashkent, Almaty, Makhachkala, Bishkek, Novosibirsk, Ashgabat, Nalchik, Kazan,

Elista, Ufa and other cities. Prof. M. Zakiev also presented Tatar linguistics at foreign forums. Academician M. Zakiev was an invited participant at the events held in the USA, England, Germany, Hungary, Yugoslavia, Turkey and Vietnam.

Along with his fundamental works related to phonetics, word formation, morphemics, morphology and lexicon of the Tatar language, Mirfatykh Zakiyev was one of the first in Turkology to explain the foundations of Turkish morphonology and ethnonyms. His findings were described in his works "Emergence of the Language of the Tatar People" [5]; "The Origin of Turks and Tatars" [6]; "Volga Bulgarians and Their Descendants" [7]; "Issues of the Language and Origin of the Volga Tatars" [8]; "Tatar: Issues of History and Language" [9]; "Turkic-Tatar Ethnogenesis" [10], "Deep Ethnic Roots of Turkic Peoples" [11]; "Ethnogenesis of Turks, Bulgarians and Bashkirs" [12]; "Ancient Turkic Onomastics and Its Morphonology" [13] and in other monographs and numerous articles.

In Tatar linguistics, many volumes of fundamental works on Tatar grammar and Tatar lexicology were prepared under the guidance of the scholar. M. Zakiyev was the scientific leader of the team of authors who published the three-volume "Tatar Grammar" (1992–1993 [14]; the expanded second edition [15] in the Tatar language was published in 2015–2017), and "Tatar Lexicology", which was written in the Tatar language (in 3 volumes, 2015–2018) [16].

M. Zakiev was an expert in ethnic history of the Turks. Loyal to the Kazan School of Turkology, the scholar focused his linguistic research on studying the ethnic history of the Turks and Bulgarian Tatars. He believed that in the process of learning ethnic history problems, it is necessary to study the history of Turkic languages, including the Bulgar-Tatar language.

His more than 800 research works, including 60 monographs, educational materials, programs and textbooks, prepared for higher and general educational institutions teaching the Tatar language, are devoted to the issues of the Tatar language, the history of the Tatar people, the ethnic history of the Turkic peoples, inter-ethnic and inter-linguistic relations, to the issues of bilingualism and multilingualism. M. Zakiev founded scientific schools in Tatar linguistics in the field of studying Tatar syntax, interlinguistic relations, bilingualism, multilingualism and they are still active today.

As a scholar and a mentor, Mirfatykh Zakiyev trained about 60 candidates of science and 18 doctors of science. They are doing imortant research today following the path of their mentor.

M. Zakiev's multifaceted activities were highly appreciated outside Tatarstan. In 1990, he was elected a member of the World Parliament of the Knights of Earth Life in Australia. In 1991, he got the Order of the White Cross by the Board of the Parliament for Ecology of Nations (ethnoecology).

In 1990–1991, M. Zakiyev's biography was included in various international biographical guides. For example, the International Biographical Center of Cambridge (England) added his academic biography to the collection "Who Is Who?". At the end of 1992, this Center held a competition of biographies of famous people from more than 80 countries of the world, based on computer data. According to their results, Academician M. Zakiev was awarded the honorary title "International Person of the Year 1992" for his works in recent years. For his administrative, research and teaching activities, he was awarded the medal "For Achievements of the 20$^{th}$ Century".

M. Zakiev's research work was highly appreciated. He was awarded the Order of the Red Banner, Order of Labor, Order of Friendship of Peoples and Orders for achievements in the Republic of Tatarstan, numerous medals and honorary titles. In 1970, the scholar was awarded the honorary title of an Honored Scientist of the TASSR, and in 1976, the Honored Scientist of the RSFSR. In 1994, M. Zakiev got the State Prize of the Republic of Tatarstan in the field of science and technology, from 2013 he was an emeritus professor of Kazan University.

**References**

1. Zakiyev, M. Z. (1962). *Sintaksicheskii stroi tatarskogo yazyka: v 2 t.: dissertatsiya ... doktora philologicheskikh nauk: 10.00.00* [Syntactic Structure of the Tatar Language: In 2 Volumes: Doctor of Philology Thesis]. Kazan', 1148 p. (In Russian)

2. Zakiyev, M. Z. (1958). *Khazerge Tatar adabi tele. Syntaxis* [Modern Tatar Literary Language. Syntax]. 244 p. Kazan, Kazan Universitety Nashriyaty. (In Tatar)

3. Zakiyev, M. Z. (1963). *Sintaksicheskii stroi tatarskogo yazyka* [Syntactic Structure of the Tatar Language].464 p. Kazan', izd-vo Kazan. un-ta. (In Russian)

4. Zakiyev, M. Z. (2013). *Tatar telenen syntaxik tozeleshe* [Syntactic Structure of the Tatar Language]. 392 p. Kazan, Ikhlas. (In Tatar)

5. Zakiyev, M. Z. (1977). *Tatar halky telenen barlykka kilue* [The Emergence of the Tatar People's Language]. 208 p. Kazan, Tatarstan Kitap Nashriyati. (In Tatar)

6. Zakiyev, M. Z. (2002). *Proiskhozhdenie tyurkov i tatar* [The Origin of the Turks and Tatars]. 496 p. Moscow, Insan. (In Russian)

7. Zakiyev, M. Z., Kuzmin-Ummanadi, Ya. F. (1993). *Volzhskie bulgary i ikh potomki* [Volga Bulgarians and Their Descendants]. 160 p. Moscow, Insan, Rossiya Madaniyat Fondy. (In Russian)

8. Zakiyev, M. Z. (1986). *Problemy yazyka i proiskhozhdeniya volzhskikh tatar* [Issues of the Volga Tatars' Language and Origin]. 304 p. Kazan, Tatarskoe knizhnoe izdatel'stvo (In Russian)

9. Zakiyev, M. Z. (1995). *Tatary:Problemy istorii i yazyka* [Tatars: Problems of History and Language]. 464 p. Kazan', Inst. yazyka, liter.i istorii. (In Tatar)

10. Zakiyev M. Z. (1998). *Turki-Tatar etnogenesy* [Turkic-Tatar Thnogenesis]. 624 p. Kazan, Fiker. Məskəү, Insan. (In Tatar)

11. Zakiyev, M. Z. (2011). *Glubokie etnicheskie korni tyurkskikh narodov* [Deep Ethnic Roots of the Turkic Peoples]. 400 p. Astana, "Turkskaya Akademiya". (In Russian)

12. Zakiyev, M. Z. (2011). *Etnogenez tyurkov, bulgar i bashkir* [Ethnogenesis of the Turks, Bulgars and Bashkirs]. 704 p. Ufa, izd-vo AN RB "Gilem". (In Russian)

13. Zakiyev, M. Z. (2013). *Drevnetyurkskaya onomastika i eye morfonologiya* [Ancient Turkic Onomastics and Its Morphonology]. 416 p. Astana, TOO Prosper Print. (In Russian)

14. *Tatarskaya grammatika: v 3 tomakh* (1993) [Tatar Grammar: In 3 Volumes]. T. 1, 583 p. Kazan, Tatarskoe kn. izd-vo; Tatarskaya grammatika: v 3 tomakh (1993) [Tatar Grammar: In 3 Volumes]. T. 2, 397 p. Kazan, Tatarskoe kn. izd-vo; Tatarskaya grammatika: v 3 tomakh (1995) [Tatar Grammar: In 3 Volumes]. T. 3, 576 p. Kazan, Tatarskoe kn. izd-vo. (In Russian)

15. *Tatar grammatikasy: 3 tomda* (2015) [Tatar Grammar: In 3 Volumes]. Proyekt gitakchese M. Z. Zakiev; red. F. M. Khisamova. T. 1, 512 p. Kazan, Tel, adabiyat ham Tarikh instituty; *Tatar grammatikasy: 3 tomda* (2017) [Tatar Grammar: In 3 Volumes]. Proyekt gitakchese həm avtor M. Z. Zakiev. - 2 nche chygarylysh. T. 3, 536 p. Kazan, Tel, adabiyat ham Tarikh instituty. Tulylandyrylgan 2nche basma. (In Tatar)

16. *Tatar leksikologiyase: 3 tomda* (2015) [Tatar Lexicology: In Three Volumes]. Proyekt gitakchese M. Z. Zakiev; red. G. R. Galiullina. T. I, 352 p. Kazan, Tel, adabiyat ham Tarikh instituty; *Tatar leksikologiyase: 3 tomda* (2017) [Tatar Lexicology: In Three Volumes]. Proyekt gitakchese M. Z. Zakiev; red. G. R. Galiullina. T. 3, 536 p. Kazan, Tel, adabiyat ham Tarikh instituty. 3 tomda, 1 kis. (In Tatar)

---

# ДӨНЬЯГА ТАНЫЛГАН ТЮРКОЛОГ ЗӘКИЕВ МИРФАТЫЙХ ЗӘКИ УЛЫ

**Гөлшат Рәис кызы Галиуллина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
Gulshat.Galiullina@kpfu.ru.

**Әлфия Шәүкәт кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
alyusupova@yandex.ru.

Татар теле белемендә тирән эз калдырган галимнәр йолдызлыгында Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев гаять дәрәҗәдә әһәмиятле урын били.

Галим 1928 нче елның 14 нче августында Татарстан Республикасы Ютазы (хәзерге Баулы) районы Зәйпе авылында туа. Балачагы сугыш чоры авыл тормышында үткәнлектән, ул кечкенәдән физик хезмәт авырлыгын тоеп, өлкән ир-атлар башкара торган эшләрне эшләп үсә. 1946 нче елда М.З. Зәкиев Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегенә укырга керә. Белемгә, фәнгә омтылыш, җаваплылык кебек сыйфатлар аңа 1951 нче елда университетны бик яхшы билгеләренә генә тәмамларга һәм СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалындагы аспирантурага укырга керергә мөмкинлек бирә. 1954 нче елда ул аспирантураны вакытыннан алда филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклап тәмамлый. Шул елдан галимнең тормыш юлында яңа – Казан дәүләт университеты чоры башлана: яшь белгеч татар теле һәм әдәбияты кафедрасының өлкән укытучысы буларак педагогик эшчәнлегенә юл саба. Эрудицияле яшь галимне тиз арада иҗтимагый эшчәнлеккә дә тарта башлыйлар, ул университетның филология һәм тарих

факультетының партия оешмасы сәркатибе итеп билгеләнә. Мирфатыйх Зәки улы 1960–1965 нче елларда татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире вазифаларын башкара.

1963 нче елда «Татар теленең синтаксик төзелеше» дигән темага филология фәннәре докторлыгына диссертация яклый [1]. Әлеге хезмәткә бәйле шуны әйтергә кирәк: татар теле белемендә беренчеләрдән булып, М.З. Зәкиев татар синтаксисын комплекслы өйрәнеп, фәнни хезмәт әзерли, югары уку йортлары студентлары өчен татар синтаксисы буенча курсны гамәлгә куя. Соңрак әлеге хезмәт башка төрки халыклар өчен үрнәк-өлге вазифасын башкарды. Галим тарафыннан төрле елларда әзерләнгән «Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис» [2]; «Синтаксический строй татарского языка» [3]; «Татар теленең синтаксик төзелеше» [4] хезмәтләре хәзерге көндә татар теленең грамматик төзелешен тулаем чагылдырган хезмәтләрнең иң лаеклысы санала.

Галим тормышының икенче гаять җаваплы эшчәнлек чоры Казан дәүләт педагогия институты белән бәйле. Фәнни эшчәнлеген иҗтимагый, оештыру эшләре белән бергә тыгыз бәйләнештә алып барган М.З. Зәкиевне 1965 нче елда Казан дәүләт педагогия институты проректоры, 1967 нче елда ректор итеп билгелиләр. Әлеге вазифада ул 1986 нчы елга кадәр эшли. 1980–1990 нче елларда ТАССР Югары Советы рәисе вазифаларын да башкара.

1986 елда Мирфатыйх Зәки улы СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры вазифаларына керешеп, институтның мөстәкыйль статус алуына ирешә, аның үсешенә гаять күп көч кертә. Әлеге вазифада галим 2000 нчы елга кадәр эшли. 1986–2014 нчы елларда – Татарстан Фәннәр академиясенең тел белеме бүлеге мөдире. 2014 елдан вафатына кадәр шул ук институтның лексикология һәм диалектология бүлегенең баш гыйльми хезмәткәре вазифаларын үти.

М.З.Зәкиев кайда гына эшләсә дә, үзе белем алган һәм хезмәт юлын башлаган Казан университеты белән элемтәсен өзмәде. Озак еллар чакырылган профессор буларак студентларга, магистрантларга белем бирде, аспирантлар белән җитәкчелек итте. 2020–2023 елларда Казан федераль университетының профессор-консультанты булды.

Мирфатыйх Зәки улы – дөньякүләм танылган, энциклопедик колачлы галим, остаз. Ул хәзерге татар теле белеменең формалашу һәм үсешендә төп рольне башкарган шәхес. Аның күпсанлы хезмәтләре татар теленең төрле тармакларына, татар халкының, татар теленең барлыкка килүенә, этногенез проблемаларына багышланган.

М.З. Зәкиев, тел белгече һәм киң профильле филолог буларак, төрле конференцияләрдә еш чыгыш ясый. Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Бакуда, Ташкентта, Алма-Атада, Махачкалада, Бишкекта, Новосибирскида, Ашхабадта, Нальчикта, Казанда, Элистада, Уфада һәм башка шәһәрләрдә үткәрелгән конференцияләрдә галимнең чыгышларын тюркологлар һәрвакыт көтеп алалар. Профессор М.З.Зәкиев татар лингвистикасын чит ил форумнарында да тәкъдим итә. АКШ, Англия, Германия, Венгрия, Югославия, Төркия, Вьетнамда үткәрелгән чараларда академик М.З.Зәкиев көтеп алынган галим була.

Мирфатыйх Зәки улы татар теленең фонетика, сүз ясалышы, морфемика, морфология, лексикасына бәйле фундаменталь хезмәтләре белән бергә, тюркология фәнендә беренчеләрдән булып, төрки морфонология, этнонимикасы нигезләрен дә бәян итә. Аның нигезләмәләре «Татар халкы теленең барлыкка килүе» [5]; «Происхождение тюрков и татар» [6]; «Волжские булгары и их потомки» [7]; «Проблемы языка и происхождения волжских татар [8]; «Татары: Проблемы истории и языка» [9]; «Төрки-татар этногенезы» [10], «Глубокие этнические корни тюркских народов» [11]; «Этногенез тюрков, булгар и башкир» [12]; ««Древнетюркская ономастика и ее морфонология» [13] һәм башка монографияләрдә, күпсанлы мәкаләләрдә чагылыш тапкан.

Татар теле белемендә галим җитәкчелегендә татар грамматикасы, татар лексикологиясе буенча күп томлы фундаменталь хезмәтләр әзерләнде. Галим татар теле белеме өлкәсендә фундаменталь саналган өч томлы «Татар грамматикасы» («Татарская грамматика», 1992-1993 [14]; татар телендә 2015–2017 елларда киңәйтелгән икенче басмасы [15] дөнья күрә), татар телендә дөнья күргән «Татар лексикологиясе» (3 томда, 2015–2018 еллар) [16] авторлар коллективының фәнни җитәкчесе дә булып тора.

М.З. Зәкиев – төркиләрнең этник тарихын өйрәнгән белгеч. Казан тюркология мәктәбенә тугрылыклы булып, галим үзенең лингвистик тикшеренүләрен төркиләрнең һәм болгар-татарларның этник тарихын ачыклауга юнәлтә. Ул этник тарих проблемаларына төрки телләр,

шул исәптән болгар-татар теле тарихын тикшерүне дә кирәк дип саный.

Аның 800дән артык фәнни хезмәте, шул исәптән 60 монографиясе, уку-укыту әсбаплары, татар теле буенча югары һәм гомуми белем бирү оешмаларына әзерләнгән программалар һәм дәреслекләр татар теле проблемаларына, татар халкы тарихы, төрки халыкларның этник тарихы милләтара һәм телара мөнәсәбәтләр, ике- һәм күптеллелек проблемаларына багышланган. М.З. Зәкиев тарафыннан татар теле белемендә татар синтаксисы, телара багланышлар, ике-, күптеллелек мәсьәләләрен өйрәнү юнәлешендә фәнни мәктәпләр булдырылды һәм алар бүгенге көндә дә актив эшчәнлек алып бааралар.

Галим һәм остаз буларак, Мирфатыйх Зәки улы җитәкчелендә 60 ка якын фән кандидаты һәм 18 фән докторы әзерләде. Алар бүгенге көндә галимнең фәндә салган юлын дәвам итүдә зур эш башкаралар.

М.З. Зәкиевнең күп яклы эшчәнлеге Татарстаннан читтә дә югары бәяләнә. 1990 елда ул Австралиядә урнашкан җирдәге тормышны саклау буенча Бөтендөнья рыцарьлар парламенты әгъзасы итеп сайлана. 1991 елда М.З. Зәкиев милләтләр экологиясе буенча (ягъни этноэкология) парламент җитәкчелеге тарафыннан Ак Хач ордены белән бүләкләнә.

1990-1991 елларда М.З. Зәкиев биографиясе төрле халыкара биографик белешмәлекләргә кертелә. Мәсәлән, Кембридж (Англия) халыкара биографик үзәге аның фәнни биографиясен «Кто есть кто? » җыентыгына кертә. 1992 елның ахырында бу үзәктә компьютер мәгълүматлары буенча дөньяның 80 нән артык иленнән танылган шәхесләрнең биографияләре конкурсы уздырыла. Аларның нәтиҗәләре буенча академик М.З. Зәкиевка соңгы еллардагы хезмәтләре өчен «1992 елның халыкара ел кешесе» дигән мактаулы исем бирелә. Административ, фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлектәге өчен ул «XX гасыр казанышлары өчен» медале белән бүләкләнә.

М.З. Зәкиевнең гыйльми эшчәнлеге югары бәяләнә. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен орденнары, күпсанлы медальләр, мактаулы исемнәр иясе. Галим 1970 елда ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, 1976 елда РСФСРның атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә лаек була. 1994 елда М.З.Зәкиевкә Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе бирелде, 2013 елдан ул Казан университетының атказанган профессоры иде.

**Әдәбият**


1. Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка: в 2-х т.: диссертация … доктора филологических наук: 10.00.00. Казань, 1962. 1148 с.
2. Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис. Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 1958. 244 б.
3. Зәкиев М.З. Синтаксический строй татарского языка» Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1963. 464 с.
4. Зәкиев М.З. Татар теленең синтаксик төзелеше. Казан: Ихлас, 2013. 392 б.
5. Зәкиев М.З. Татар халкы теленең барлыкка килүе. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1977. 208 б.
6. Закиев М.З. Происхождение тюрков и татар. М.: Инсан, 2002. 496 с.
7. Закиев М.З., Кузьмин-Юманади Я.Ф. Волжские булгары и их потомки. М.: ИНСАН, Российский фонд культуры, 1993. 160 с.
8. Закиев М.З. Проблемы языка и происхождения волжских татар. Казань: Татарское книжное издательство, 1986. 304 с.
9. Закиев М.З. Татары: Проблемы истории и языка». Казань: Ин-т яз., лит. и истории, 1995. 464 с.
10. Зәкиев М.З. Төрки-татар этногенезы. Казан: Фикер, Мәскәү: Инсан, 1998, 624 б.
11. Закиев М.З. Глубокие этнические корни тюркских народов. Астана: «Тюркская академия», 2011. 400 с.
12. Закиев М.З. Этногенез тюрков, булгар и башкир. Уфа: Изд-во АН РБ «Гилем» Изд-во АН РБ «Гилем» , 2011. 704 с.
13. Закиев М.З. Древнетюркская ономастика и ее морфонология. Астана: ТОО «Prosper Print», 2013. 416 с.
14. Татарская грамматика: в 3-х томах. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. Т. 1. 583 с.; Татарская грамматика: в 3-х томах. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. Т. 2. 397 с.; Татарская грамматика: в 3-х томах. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. Т. 3. 576 с.
15. Татар грамматикасы: 3 томда / проект җит. М. З. Закиев; ред. Ф. М. Хисамова. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. 1. 512 б.; Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм автор М.З.Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2017. – III. т. – 536 б.
16. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р.Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т. I. – 352 б.; Татар лексикологиясе / проект җит. М. З. Зәкиев; ред. Г. Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 3 т-да: Т. III. 1 кис. – 536 б.